| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |

с. Татарское Бурнашево

19.09.2017 № 29-133

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты, Бурнаш авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Бурнаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын тәкъдим итү:

«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Татар Бурнашы авылында Совет урамыннан Первомайская урамындагы чокыр аша җәяүлеләр күпере төзү;
- Гаврилково, Каинки, Ломовка, Тихий Плес, Юматово авылларында урнашкан зиратларны төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин